**КАРАР № 52**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге Советы утырышы

16 май 2022 ел Кышлау авылы

**Кышлау авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 107 номерлы карары белән расланган “Кышлау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керү сәбәпле һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү (2022 елның 14 мартына үзгәрешләр керү белән бәйле), 2021 нче елның 29 нчы ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Кушымта нигезендә Кышлау авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 107 номерлы карары белән расланган “Кышлау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы А.Х.Кашшапов

Кышлау авыл җирлеге Советының
2022 нче елның 16 маендагы
52 нче номерлы карарына кушымта

Кышлау авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 107 номерлы карары белән расланган “Кышлау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. **16 статьяның 23 абзацында**, йөкләмәләр сүзләреннән соң «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга һәм «валюта» сүзеннән соң «бирелгән» сүзен ««бирелгәннәр» сүзе белән алмаштырырга;

2. **20 статьяның 2 өлешендә**, "җирлек" сүзеннән соң «тиешле ел ахырына файдаланылмаган инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының калдыгы " сүзләрен өстәргә;

3. **6 статьяда**:
   а) түбәндәге эчтәлекле унынчы абзацны өстәргә:
   “-бюджет процессында гражданнарның катнашуы;”;
   б) унынчы - унөченче абзацларны унберенче – ундүртенче абзацлар дип санарга.